БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1 ноябрь 2018 ел № 152

Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлаулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисенә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Социаль гарантияләр белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында хезмәт өчен түләү системасы үзгәрүгә бәйле, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы

сайлаулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисенә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 14 пунктчаны өстәргә:

«14) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затларга Татарстан Республикасы мактаулы исеме өчен 17/1 нче кушымта нигезендә айлык өстәмә түләү күләме һәм тәртибе.» (кушымта булып бирелә).

2. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.».

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе һәм муниципаль хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру тәртибенеж (20 нче кушымта) 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Балтач шәһәр җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме – елына 8,59 айлык акчалата бүләкләүне, Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары өчен хезмәткә түләүнең 11 төркеменә кертелгәннәргә - елына 7,71 айлык акчалата бүләкләүне, Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары өчен хезмәткә түләүнең 12 төркеменә кертелгәннәргә - елына 6,72 айлык акчалата бүләкләүне, Балтач шәһәр җирлеге башлыгы урынбасарына - елына сигез айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итә».

4. Әлеге карарның 3 пункты 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин